ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 12

Урыссу ш.т.п. 27.07 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 ел, № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль Законга, «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында»гы 10.01.2003 № 17-ФЗ Федераль Законга, «Россия Федерациясенең “Җир асты байлыклары турында”гы Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 14.07.2022 № 343-ФЗ Федераль законы нигезендә, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.2021 №14-П “Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 209 статьясы 2 пунктының конституционлыгын тикшерү турында”гы эш буенча, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» Федераль законның 10 статьясы 7 өлеше нигезендә, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 статьясы 1 өлешендәге егерме икенче абзацы, 16 статьясы 1 өлеше 25 пунктының һәм 45.1 статьясы 2 өлеше 3 пункты нигезендә, Г.С. Дадашов, И.Н. Касыймов һәм башка гражданнарның шикаятьләренә бәйле рәвештә , "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кама транспорт прокуратурасының 21.03.2023 ел, № 23/1-02-2023 " Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 № 23 карары белән расланган (08.09.2020, 28.01.2022, 30.03.2022, 01.03.2023 карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә Протесты нигезендә, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә (08.09.2020 № 15, 28.01.2022 № 4, 30.03.2022 № 8, 01.03.2023 № 4 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрнең 2.1 пунктының 64 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба - калдыклар) - «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" 24.06.1998 ел, № 89-ФЗ Федераль закон нигезендә алына торган, алыну өчен билгеләнгән яки алынырга тиешле җитештерү, эш башкару, хезмәт күрсәтү процессында яисә куллану процессында барлыкка килгән матдәләр яки предметлар, шулай ук Россия Федерациясенең 21.02.1992 ел № 2395-I номерлы «Җир асты байлыклары турында»гы Законына ярашлы, казылма байлыкларын каплаган һәм яшергән тау токымнары.»;

1.2. Кагыйдәләрнең 4.6.1 пунктының "л" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"л) коммуналь билгеләнештәге объектларны, инженерлык коммуникацияләрен (корылмалар), юлларны, күперләрне, җәяүлеләр үтү урыннарын төзегәннән, реставрация, археология һәм башка җир эшләре үткәргәннән, реконструкцияләгәннән һәм ремонтлаганнан соң төзекләндерүнең бозылган элементларын торгызу»;

1.3. Кагыйдәләрнең 5.1 пунктындагы "д" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) җәмәгать транспортының тышкы яктырту терәкләрен һәм контакт челтәре терәкләрен ремонтлау;»;

1.4. Кагыйдәләрнең 9.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.7. Тышкы яктырту терәк баганалары, җәмәгать транспортының контакт челтәре терәк баганалары, саклагыч, аергыч ихаталар, юл корылмалары һәм юл җиһазлары элементлары буялырга, язулардан һәм теләсә нинди мәгълүмати-басма продукциядән чистартылырга, төзек хәлдә һәм чисталыкта тотылырга тиеш.»;

1.5. Кагыйдәләрнең 9.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8. Тышкы яктырту терәк баганаларын, җәмәгать транспорты контакт челтәренең терәкләрен алыштырганда, әлеге конструкцияләр өч тәүлек эчендә сүтелергә һәм челтәр хуҗалары тарафыннан чыгарылырга тиеш.

Тышкы яктыртылышның ауган терәкләрен чыгару юлларда - терәк хуҗасы тарафыннан шунда ук, калган территорияләрдә мондый ихтыяҗ ачыкланганнан соң (демонтажланганнан соң) бер тәүлек дәвамында башкарыла.»;

1.6. Кагыйдәләрнең 9.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.9. Яктырту терәк баганаларында һәм җәмәгать транспорты контакт челтәренең терәк баганаларында урнаштырылган барлык элементларның һәм объектларның төзек һәм куркынычсыз торышы һәм канәгатьләнерлек тышкы күренеше өчен әлеге терәк баганаларының милекчесе (хуҗасы) җаваплы.»;

1.7. 15.8.3 пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"а) юл һәм урам киселешләрендә бер дәрәҗәдә;»;

1.8. 15.11.3 пунктның «н» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"н) теләсә нинди сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен, шул исәптән палаткалар, киосклар, лареклар, мини-базарлар, павильоннар, җәйге кафелар, җитештерү объектларын, көнкүреш техникасын, аяк киемнәрен, автомобильләрне вак ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук “гостевойлардан” тыш, автотукталышлар урнаштырырга.

Тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында Карар кабул итәләр;»;

1.9. Кагыйдәләрнең 19 нчы пункты “п” пунктчасы алып ташларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе, Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Урыссу
шәһәр тибындагы поселогы Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин